# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылышның чираттан тыш утырышы

**КАРАРЫ**

25 июнь 2025 ел №23 Урыссу ш.т.б.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 25.04.2018 ел № 11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы депутатларының, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, "Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында"гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 маендагы 182 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында"гы 14.04.2025 ел, № 228 карары нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 25.04.2018 № 11 карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы депутатларына, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, контроль-хисап органнары рәисләренә, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегенең 1 пунктында "13 990" саннарын "15389" саннарына алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 1 бүлегенең 6 пунктында "14,12" саннарын «16,85» саннарына, «12,86» саннарын «15,48» саннарына алмаштырырга.;

1.3. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 6 пунктында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «41 процент» сүзләрен «58 процент» сүзләренә алмаштырырга;

1.5. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә яңа

редакциядә бәян итәргә;

1.6. Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Ютазы муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә элек кабул ителгән хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының Бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин

Сучкова А.В.
8(85593)2-80-12

Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2025 елның "25" июнендәге 23 санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районында муниципаль берәмлек башлыгын, муниципаль берәмлекләр башлыгы урынбасарын, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларын, сайланулы вазыйфаи затларын, контроль-хисап органы рәисен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | 8 группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 40 740 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 36 667 |
| Контроль-хисап органы рәисе | 36 667 |

Татарстан Республикасы Ютазы район
Советының 2025 елның "25" июнендәге
23 санлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар исемнәре | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) | | | |
|---|---|---|---|---|
| | шәһәр тибындагы поселоклар нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә | | | |
| | 9 группа | 10 группа | 11 группа | 12 группа |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 28 632 | 25 091 | 23 091 | 21 091 |